ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 июнь 2019ел № 3047

Башкарма комитетның «Хезмәт урыныннан бирелә торган торак бүлмәгә наем килешүе буенча торак бүлмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 5 мартындагы 1144 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Хезмәт урыныннан бирелә торган торак бүлмәгә наем килешүе буенча торак бүлмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3272 нче, 2018 елның 9 ноябрендәге 6595 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт урыныннан бирелә торган торак бүлмәне наемга алу килешүе буенча гражданнарга торак бүлмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

2) 1 пунктта «торак бүлмәләр бирү» сүзләрен «гражданнарга торак бүлмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «торак бүлмәләр бирү» сүзләрен «гражданнарга торак бүлмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

4) хезмәт урыныннан бирелә торган торак бүлмәне наемга алу килешүе буенча гражданнарга торак бүлмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

- 1 нче кушымтаның номерланган исемендә «торак бүлмәләр бирү» сүзләрен «гражданнарга торак бүлмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин